**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР**
**2018 елның 31 августы**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 241**

**Биектау муниципаль районының интегральләшкән тулы текстлы хокукый мәгълүмат банкына кертелгән җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары турында (хокукый мәгълүматның күрсәткечләр эталон банкы)**

Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокукый актларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм электрон рәвештә хокукый актлар таратуның дәүләт системасын булдыруда катнашу максатында, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россиянең хокукый мәгълүматлаштыру концепциясе турында» 1993 елның 28 июнендәге 966 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Федераль законнар нигезендә дәүләт саклавы органнары тарафыннан таратыла торган «Россия законнары» хокукый мәгълүматның тулы текстлы банкына (хокукый мәгълүматның эталон банкына) кертелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын рәсми текстлар диеп санарга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Совет председателе,
Район башлыгы Р.Г. Кәлимуллин